# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

« 08 » 04 2024 ел Яр Чаллы ш. № 903

2024 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләмнәрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләмнәрен билгеләү методикасы, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берләшмәсе» коммерциясез партнерлыгының 2024 елның 13 февралендәге 79 номерлы «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» бәяләмәсе нигезендә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күләмнәрне билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чиге:

- ялгыз яшәүче кеше өчен – 944 073 сум;
- ике кешедән торган гаилә өчен - 1 888 146 сум;
- өч кешедән торган гаилә өчен - 2 832 219 сум;
- дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 776 292 сум;
- биш кешедән торган гаилә өчен- 4 720 365 сум;
- алты кешедән торган гаилә өчен – 5 664 438 сум;
– җиде кешедән торган гаилә өчен – 6 608 511 сум;
- сигез кешедән торган гаилә өчен – 7 552 584 сум;

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

- ялгыз яшәүче граждан өчен – 26 437 сум 73 тиен;
– ике кешедән торган гаилә өчен - 26 437 сум 74 тиен;
- өч һәм аннан артык кешедән торган гаилә өчен - 22 027 сум 44 тиен.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарда күрсәтелгән максималь чик күрсәткечләрне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алганда кулланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яки Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин